ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АГРАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 83-3 29.01.2020 ел.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советының "Бюджет төзелеше турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2019 елның 8 октябрендәге 72-2 номерлы карары белән расланган муниципаль берәмлектә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре системасы өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Советының "Бюджет төзелеше турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2019 елның 8 октябрендәге 72-2 номерлы карары белән расланган муниципаль берәмлектә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 15 статьясындагы 14 абзацында «акчаларны исәпкә алу» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Нигезләмәнең 45 статьяның 3 пунктында «түләүле һәм» сүзләрен «казначылык түләүләрен башкару турында боерыклар (алга таба - боерык) һәм» сүзләренә алмаштырырга, «түләү документлары» сүзләрен «боерыклар» сүзенә алмаштырырга.

1.3.Нигезләмәнең 45 статьясындагы 5 пунктында «түләү документлары» сүзләрен «күрсәтмәләр» сүзенә алмаштырырга.

1.4. Нигезләмәнең 48 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацында «касса» сүзен «казначей» сүзенә алмаштырырга;

2. Әлеге карар 2021 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Аграмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru), һәм хокукый мәгълүмат сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге башлыгы Р.Т. Галәветдинова

СОВЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ